ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№17 от 10.06.2020 года

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ким авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында квартал саен белешмәләр бастырып чыгару тәртибен раслау хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, муниципаль Ким авыл җирлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ким авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Ким авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны турында квартал саен белешмәләрне һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнарны бастырып чыгару тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Ким авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Гисматов

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ким
авыл җирлеге башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта
2020 елның 10 июненнән № 17

## Ким авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында квартал саен белешмәләр бастырып чыгару тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Ким авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында квартал саен бирелә торган белешмәләрне бастырып чыгару тәртибе (алга таба - Тәртип) "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, Ким авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. Тәртип Ким авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә фактик чыгымнар турында квартал саен бирелә торган мәгълүматларны (алга таба - белешмәләр) тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели.

## II. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында белешмәләрне тапшыру һәм аларның составы

2.1. Белешмәләр квартал саен җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең уртача исемлек саны турында, шул исәптән хисап чорында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Ким авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре турында, шулай ук хисап чорында хезмәт хакына карата түләүләрне исәпкә алмыйча, хезмәт өчен түләү чыгымнарын гамәлгә ашыруга фактта җибәрелгән бюджет ассигнованиеләре күләмен (акчалата тотуны) чагылдыра.

2.2. Белешмәләр хисап чорыннан соң килә торган айның 5 числосына кадәр әлеге Тәртипкә кушымта нигезендәге рәвеш буенча тапшырыла.

2.3 Ким авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә мәгълүмат формалаштыра.

## III. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләрне бастырып чыгару тәртибе

3.1. Ким авыл җирлегенең башкарма комитеты хисап чорыннан соң килүче айның соңгы санынннан да соңга калмыйча Ким авыл җирлеге башкарма комитетының белешмәләрне раслау турындагы карары проектын әзерли.

3.2 Ким авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган белешмәләр хисаптан соң килүче икенче айның соңгы санына кадәр Ким авыл җирлеге сайтында бастырып чыгарылырга тиеш.

Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәрләре
саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы
чыгымнар турында квартал саен бирелә торган
белешмәләрне бастырып чыгару тәртибенә кушымта

# Ким авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең саны һәм аларның хезмәте өчен хисап чорының_______________20___елгы түләүгә факттагы чыгымнар турындагы белешмәләр (беренче квартал, яртыеллык, тугыз ай, бер ел)

| Хезмәткәрләр категориясе | Хисап чорында хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны, кеше | Хисап чорында хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнар, мең сум |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ким авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре | | |
| шул исәптән: муниципаль хезмәткәрләр | | |